МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.10.2023 г.Казань № 384/2-пр

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә б о е р а м:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәне;

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе составын.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2016 елның 24 мартындагы 49/2-пр номерлы;

«Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2018 елның 22 мартындагы 57/2-пр номерлы;

«Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2016 елның 24 мартындагы 49/2-пр номерлы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 16 февралендәге 40/2-пр номерлы.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2023 елның 13 октябрь 384/и-пр номерлы боерыгы белән расланды

**Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә, Комиссия, Министрлык) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы 569-ПУ номерлы Указы нигезендә эшләнде һәм Комиссия төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы түбәндәгеләрне башкаруда ярдәм итү:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәүләрен (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтыны җайга салу турында таләпләр) тәэмин итүдә;

Министрлыкта коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруда.

1.4. Комиссия Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфасын) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата (билгеләп кую һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле

мәсьәләләрне карый.

1.5. Министрлыкта билгеләп кую һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибе таләпләренең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлүенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында Хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия (алга таба - Комиссия) тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр турында һәм административ хокук бозулар турында кергән хәбәрләрне, шулай ук исемсез (аноним) мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) тарафыннан билгеләнеп куела торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, шулай ук Комиссия секретаре һәм әгъзалары составында төзелә.

Карарлар кабул иткәндә Комиссиянең барлык әгъзалары тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкның кадрлар бүлегеннән коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи зат (Комиссия секретаре), Министрлыкның кадрлар бүлегеннән, юридик бүлегеннән, башка бүлекчәләреннән министр тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) фәнни оешмаларның, һөнәри белем бирү оешмаларының, югары белем бирү оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының эшчәнлеге дәүләт хезмәтенә бәйле вәкиле (вәкилләре).

2.3. Министр Комиссия составына Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет, Министрлыкның башлангыч һөнәр берлеге оешмасы вәкилләрен кертү турында карар кабул итәргә мөмкин.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар министр үтенечнамәсе нигезендә, тиешле органнар һәм оешмалар белән килештереп, билгеләнгән тәртиптә Комиссия составына кертеләләр. Килештерү үтенечнамә алынган көннән 10 көн эчендә башкарыла.

2.5. Комиссиянең Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләмәүче әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга

тәэсир итәрлек мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеген булдырмаслык итеп төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында киңәш бирү тавышы хокукы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) хезмәт тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлүе турында Комиссия тарафыннан үзенә карата мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе билгеләве буенча - Министрлыкта Комиссия тарафыннан үзенә карата әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре биләгән шундый ук вазыйфаны биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алырлык белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынучы оешмаларның вәкилләре; хезмәт тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлүе турында Комиссия тарафыннан үзенә карата мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле - үзенә карата әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы үтенечнамәсе нигезендә, Комиссия утырышы көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, һәр конкрет очракта кабул ителә торган Комиссия рәисе карары буенча.

2.8. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала. Утырышларны Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда Комиссия әгъзасында мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яисә читләтеп шәхси кызыксынучанлык барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчы бу хакта белдерергә тиеш. Андый очракта Комиссиянең шул әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслегенә һәм тулылыгына һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан дәүләт хезмәтенә таләпләрнең үтәлүенә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә тикшерү уздыру нәтиҗәләре буенча министрның түбәндәгеләрне таныклый торган материаллар тапшыруы:

Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт, мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылуы турында;

дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлмәве турында;

б) Министрлыкның норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә кадрлар бүлегенә түбәндәгеләр кергән булса:

Министрлыкта вазыйфа биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Министрлык боерыгы белән расланган исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирүе турында мөрәҗәгате - әгәр дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән ике ел узганчы әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычлары составына кергән булса;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирә алмау турындагы гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гаризасы - территориясендәге банкта счетлары (кертемнәре) булган, акчалары һәм кыйммәтле әйберләре саклана торган һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары булган чит дәүләт законнары нигезендә кулга алынуы, алар белән эш итү компетентлы органнар тарафыннан тыелуга бәйле рәвештә яисә аның ихтыярына яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартларга бәйле рәвештә;

дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәрнамәсе;

в) министрның яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен тәэмин итүгә яисә Министрлыкта коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруга кагылышлы күрсәтмәсе;

г) министр тарафыннан дәүләт хезмәткәренең «Дәүләт вазыйфасын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыруын таныклый торган тикшерү материаллары тапшырылу;

д) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә Министрлыкка коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмадан элек Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эшләр башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокук шартнамәсе төзү турында

кергән хәбәрнамә, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның Министрлыкта вазыйфа биләгән вакытта башкарган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, шулай ук әлеге гражданга шушы оешма белән хезмәт һәм граждан-хокук мөнәсәбәтләренә керүне элегрәк Комиссия хупламаган булса яисә мондый гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирү турындагы мәсьәлә Комиссия тарафыннан каралмаган булса.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан Министрлыкның кадрлар бүлегенә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булса) , туган көне, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән соңгы ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың исеме, урнашкан урыны, аның эшчәнлегенең үзенчәлеге, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгәндә граждан тарафыннан башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре, шартнамә төре (хезмәт яисә граждан-хокук), аның күздә тотылган гамәлдә булу срогы, шартнамә буенча башкарган эшләр (күрсәткән хезмәтләр) өчен түләү суммасы. Мөрәҗәгать Министрлыкның кадрлар бүлегендә карала, аның нәтиҗәләре буенча, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилле бәяләмә әзерләнә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне дәүләт хезмәтеннән үзенең китүен планлаштыручы дәүләт хезмәткәре бирә ала һәм ул әлеге Нигезләмә нигезендә Комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат карый, ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12 статьясы таләпләре үтәлеше турында дәлилле бәяләмә әзерли.

3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамәне коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат карый, ул хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә әзерли.

3.4.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә әзерләгәндә, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат мөрәҗәгатьне яисә хәбәрнамәне биргән дәүләт граждан хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә һәм аңардан язма аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Министрлык тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрелергә мөмкин, шул исәптән коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын кулланып. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә

кергән көннән җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән озаграк булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.

3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган дәлилле бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынучы оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә кабул ителгән карарларның берсе яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.

3.5. Комиссия рәисе, үзенә Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат кергәндә:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы датасы, әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән датадан 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнергә тиеш.

б) үзенә карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт граждан хезмәткәре белән, аның вәкиле, Комиссия әгъзалары һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затлар белән, кадрлар бүлегенә кергән мәгълүмат белән, шулай ук күрсәтелгән мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән танышуны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турындагы үтенечнамәләрне карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт граждан хезмәткәре яисә Министрлыкта дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән граждан катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында дәүләт граждан хезмәткәре яисә граждан үзенең шәхсән катнашу нияте турында әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы

нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрнамәдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт хезмәткәре яисә граждан катнашыннан башка үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәгән булса;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте булган һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешле хәбәр алган дәүләт хезмәткәре яисә граждан Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яисә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана (аларның ризалыгы белән), әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган белешмәләрне фаш итәргә хокуклы түгел.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә" нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы күләмдә, дип билгеләргә;

б) әлеге пунктның беренче абзацында аталган Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес түгел һәм (яисә) тулы күләмдә түгел, дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәгән, дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән, дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне бозарга ярамаганлыгын дәүләт хезмәткәренә әйтергә йә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.13. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирергә, әгәр бу оешманың

дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

б) гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләргә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирмәскә, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, һәм рөхсәт бирмәвен дәлилләргә тиеш.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр объектив һәм мөһим сәбәпләр аркасында бирелмәгән, дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр мөһим булмаган сәбәпләр аркасында бирелмәгән, дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә әлеге белешмәләрне тапшыру өчен чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирелмәүнең сәбәбе объектив түгел һәм бу әлеге белешмәләрне тапшырудан баш тарту ысулы булып тора, дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.15. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә киртә булган шартлар объектив һәм алар мөһим шартлар, дип танырга;

б) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә киртә булган шартлар объектив түгел һәм алар мөһим шартлар түгел, дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.15.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычлар башкарылганда мәнфәгатьләр конфликты булмаган, дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычлар башкарылганда шәхси

кызыксынучанлык мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин, дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) министрга мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яисә аны булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән, дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрне дөрес һәм тулы күләмдә, дип танырга;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрне дөрес түгел һәм (яисә) тулы күләмдә түгел, дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга һәм (яисә) чыгымнарны контрольдә тоту нәтиҗәсендә алынган материалларны, компетенцияләренә карап, прокуратура органнарына һәм (яисә) башка дәүләт органнарына җибәрергә тәкъдим итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада гражданның вазыйфа биләвенә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

б) гражданның коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа биләве һәм (яисә) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада эшләр башкаруы (хезмәтләр күрсәтүе) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза, дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәрнамә җибәргән оешмага хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия, нигезләр булганда, әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.1, 3.17 - 3.18 пунктларында каралганнан тыш, башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын үтәү өчен Министрлыкның хокукый актлары, министр карарлары яисә йөкләмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә министр каравына тапшырыла.

3.21. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары аның утырышында катнашкан Комиссия әгъзалары имзалаган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карардан тыш, министр өчен тәкъдим итү характерында була. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар катгый характерда була.

3.23. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышы датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (соңгысы - булганда);

б) комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы, үзенә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы күрсәтелә;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелә торган дәгъвалар, аларны нигезли торган материаллар;

г) белдерелгән дәгъваларның асылы буенча дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (соңгысы - булганда) һәм аларның чыгышларының кыскача бәян ителеше;

е) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, Министрлыкка мәгълүмат кергән дата;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.24. Комиссиянең кабул ителгән карар белән килешмәгән әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул катгый рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә беркетелә һәм дәүләт хезмәткәре аның белән танышырга тиеш.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән җиде көн эчендә министрга, тулысынча яисә аннан өзекләр рәвешендә дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

3.26. Министр комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул иткәндә, шулай ук коррупциягә каршы көрәшүне оештыруның башка мәсьәләләре буенча анда күрсәтелгән тәкъдимнәрне үз компетенциясе чикләрендә исәпкә алырга хокуклы.

Министр Комиссия тәкъдимнәрен карау турында һәм кабул ителгән карар турында Комиссия утырышы беркетмәсе аңа кергән көннән бер ай эчендә язма рәвештә Комиссиягә хәбәр итә. Министрның карары Комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышусыз гына исәпкә алына.

3.27. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл

кылмауларында) дисциплинар хокук бозу билгеләре билгеләнгән очракта, бу хактагы мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чаралары куллану мәсьәләсен хәл итү өчен министрга җибәрелә.

3.28. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләре яисә җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу факты (гамәл кылмау факты) ачыкланган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлне кылу (гамәл кылмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый фактны раслый торган документларны хокук куллану органнарына өч көн эчендә җибәрергә тиеш, ә кирәк булганда - кичекмәстән.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аннан өземтә үзенә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшнамәсенә беркетеп куела.

3.30. Комиссия секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән расланган Комиссия карарыннан өземтә Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга кул куйдырып тапшырыла яисә, Комиссиянең тиешле утырышы уздырылган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, алу турында хәбәр бирелә торган заказлы хат итеп, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча җибәрелә.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны үткәрүнең датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышу өчен тәкъдим ителә торган материаллар белән таныштыру кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2023 елның 13 октябрь 38/4-пр номерлы боерыгы белән расланды

**Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гарипов Ленар Наил улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары, Комиссия рәисе |
| Мәхмүтов Марсель Азат улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары |
| Мостафина Рүзилә Рәшит кызы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) кадрлар бүлегенең әйдәүче белгече, Комиссия секретаре |
| | **Комиссия әгъзалары:** |
| Ибраһимов Ренат Рәшит улы | Министрлыкның аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге башлагы |
| Кәлимуллин Илнар Ирек улы | Министрлыкның юридик бүлеге башлыгы |
| Хуҗина Лилия Мөнәвир кызы | Министрлыкның кадрлар бүлеге башлыгы |
| Белосков Владимир Тимофеевич | Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы, «Земля-землица» республика иҗтимагый-сәяси газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гаязов Рөстәм<br>Камил улы | Республика Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең коррупциягә каршы мониторинг бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Гарифуллина Фәридә<br>Галимҗан кызы | Россия Федерациясе агросәнәгать комплексы хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан республика оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Шувалова Диләрә<br>Даниял кызы | «Татарстан Республикасы аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |